КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 март г.Казань № 177

«Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Попечительләр советы һәм Күзәтүчеләр советы составларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган дәүләт оешмасын төзү турында» 2004 ел, 17 ноябрь, 498 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 17 гыйнвар, 7 нче; 2005 ел, 26 май, 237 нче; 2005 ел, 28 сентябрь, 468 нче; 2005 ел, 28 сентябрь, 469 нчы; 2006 ел, 20 февраль, 66 нчы; 2006 ел, 11 декабрь, 608 нче; 2007 ел, 22 февраль, 65 нче; 2007 ел, 12 ноябрь, 623 нче; 2008 ел, 21 май, 335 нче; 2008 ел, 13 октябрь, 743 нче; 2009 ел, 25 февраль, 103 нче; 2009 ел, 24 март, 166 нчы; 2009 ел, 31 март, 193 нче; 2012 ел, 31 август, 741 нче; 2014 ел, 11 март, 152 нче; 2016 ел, 11 февраль, 83 нче; 2017 ел, 24 апрель, 243 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Попечительләр советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Попечительләр советы составына Повалко Александр Борисовичны, «Россия венчур компаниясе» акционерлык җәмгыяте генераль директорын, Идарә рәисен (килешү буенча);

Агамирзян Игорь Рубенович вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Югары икътисад мәктәбе» фәнни-тикшеренү университеты вице-президенты (килешү буенча)»;

Александра Джонсон вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Global Technology Capital компаниясенең идарәче директоры, Калифорния (килешү буенча)»;

Комиссаров Алексей Геннадиевич вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясе проректоры – Россия Федерациясе Президенты каршындагы Россия халык хуҗалыгы һәм дәүләт хезмәте академиясенең Югары дәүләт идарәсе мәктәбе директоры (килешү буенча)»;

Галицкий Александр Владимирович вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Almaz Capital Partners венчур фондының идарәче партнеры, «Элвис-плюс» акционерлык җәмгыяте президенты (килешү буенча)».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешма уставын раслау һәм «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү турында» 2016 ел, 11 февраль, 83 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 10 август, 550 нче, 2016 ел, 23 август, 586 нчы, 2017 ел, 24 апрель, 243 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган югары коллегиаль орган – «Татарстан Республикасының Инвестиция-венчур фонды» коммерциягә карамаган оешманың Күзәтүчеләр советы составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Күзәтүчеләр советы составыннан А.А.Здуновны, Э.Н.Фәттаховны, Е.В.Даутованы, Г.С.Дьяконовны чыгарырга;

Күзәтүчеләр советы составына Габделганиев Фәрид Солтан улын, Татарстан Республикасы икътисад министрын кертергә;

Борһанов Рәфис Тимерхан улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин